БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 31 » август 2018 ел № 284

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү максатларында һәм «2018-2020 елларга коррупциягә каршы көрәшнең милли планы турында» 2018 елның 29 июнендәге 378 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2014 елның 13 ноябрендәге 347 номерлы карары белән (2015 елның 18 декабрендәге 481 номерлы, 2016 елның 23 маендагы 136 номерлы, 2017 елның 15 декабрендәге 274 номерлы үзгәрешләр белән) расланган «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына (алга таба - муниципаль программа) кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа имза куйган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р. И. Шакиров